# 1 НЧЕ ЧИРЕК НӘТИҖӘЛӘРЕ

2024-2025 нче уку елында педагогик профильле гимназия сыйныфларында барлыгы 51 укучы белем ала.

7,8,9 нчы сыйныфларда Федераль белем бирү программасы буенча белем алалар. Моннан тыш өч сыйныфта да “Мөһим әйберләр турында сөйләшү”, “Россия – минем горизонт” класс сәгатьләре дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә үткәрелә.

**7 нче сыйныфның** класс җитәкчесе – Гыйләҗева Алия Фәнәвил кызы. Беренче чирек башына 7 нче сыйныфта барлыгы 11 укучы. Аларның берсе – Биектау районыннан, тулай торакта тора. Ике укучы Арча районы авылларыннан килеп йөриләр. Калган укучылар (7 укучы) Арчаның үзеннән.

Дәрестән тыш вакытта, укучылар төрле түгәрәкләргә йөриләр: йөзү, туризм, шахмат һәм шашка түгәрәкләренә йөриләр. Укучылар дәрестән тыш төрле чараларда катнашалар. 7 нче сыйныф укучылары Арча боз сараена, гимназистлар рәтенә алу чарасында, көллияттә булган төрле акцияләрдә катнашалар. Өч сыйныфта макулатура җыюда, көллият территориясен җыештыруда, чаңгы ярышларында катнаштылар.

**8 нче сыйныфның** класс җитәкчесе – Шиһабеддинова Гөлия Хәйдаровна. Беренче чирек башына 8 нче сыйныфта барлыгы 17 укучы. Аларның дүртесе – Биектау районыннан, тулай торакта торалар. Ике укучы Арча районы авылларыннан килеп йөриләр. Калган укучылар (11 укучы) Арчаның үзеннән.

Дәрестән тыш вакытта, укучылар төрле түгәрәкләргә йөриләр: йөзү, туризм, шахмат һәм шашка түгәрәкләренә йөриләр. Укучылар дәрестән тыш төрле чараларда катнашалар. 8 нче сыйныф укучылары Арча боз сараена, көллияттә булган төрле акцияләрдә катнашалар. Өч сыйныфта макулатура җыюда, көллият территориясен җыештыруда, чаңгы ярышларында катнаштылар.

“Мөһим әйберләр турында сөйләшү” кысаларында 11 нче сентябрь көнне 8 нче сыйныф укучылары “Ак барс” агрокомплексында сәяхәттә

булдылар. Укучыларны хуҗалык җитәкчесе Ленар Илсур улы Абдуллин, агрокомплексның агрономнары Сәләхов Булат Мөнир улы һәм Шәрәфиева Илүсә Зөлфәт кызы каршы алдылар. Ипинең өстәлгә ничек килүе турында мавыктыргыч итеп сөйләделәр. Иң беренче ямь-яшел булып утырган уҗымнар янында тукталдык.

“Көздән сөреп калдырылган басу тырмалана, минераль ашламалар кертелә. Берничә чәчкеч таккан трактор агрегатлары орлыкны тиешле тирәнлектә күмеп чәчәләр”, – дип сөйләде Булат Мөнирович.

Орлыклар туфракта бүртәләр һәм шытып чыгалар. Һәр бөртек җиргә тамыр җибәрә. Озак та үтми, басу ямь-яшел була. Һәр бөртектән берәр сабак үсеп чыга. Тиздән аларда башаклар барлыкка килә. Башакларда бөртекләр күренә башлый. “Игеннәр мул уңыш бирсен өчен бөртекләрне вакытында чәчү, җирне вакытында эшкәртү, ашлау кирәк”, - дип дәвам итте агроном.

Киләсе тукталыш – ындыр табагы булды. Бередә укучылар бодай, солы, арпа һ.б. бөртекле культураларны аерырга өйрәнделәр. Алга таба янә кырга чыктык. Кырларда урып-җыю эшләре дәвам итә. Комбайннар ашлыкны ура, суга, ә машиналар аларны ындыр табагына илтә. Комбайннар белән җыеп алынган ашлык амбарларда чистартылганнан соң, машиналар аны элеваторларга илтәләр. Аннары анда (тегермәндә) он тарттыралар. Оннан икмәк пешерәләр. Икмәк өстәлгә килгәнче бик күп хезмәт ияләре кулыннан үтә. Ул күп көч куеп үстерелгән ризык булуы белән дә бик кадерле шул.

**9 нчы сыйныфның** класс җитәкчесе - Яруллина Гөлназ Азатовна. Беренче чирек башында 23 кеше, өченче чиректә тагын бер укучы өстәлде, бер укучы семейное обучениега күчте. Бүгенге көндә 23 укучы белем ала. Ике укучы – Биектау районыннан, тулай торакта торалар.

Дәрестән тыш вакытта, укучылар төрле түгәрәкләргә йөриләр: йөзү, каратэ, туризм, бадминтон, түгәрәкләренә йөриләр. 9 нчы сыйныф “Акыллы бала” түгәрәгенә йөрүче балалар өчен шөгыль уздыруда, педагогик этика дәресе кысаларында үзләрен тәрбияче, укытучы ролендә сынап карадылар.

Шулай ук Казан шәһәрендә экскурсиядә булдылар, төрле тарихи урыннар белән таныштылар.

Төп дәүләт имтиханына (ОГЭга) әзерлек уку елы башыннан алып барыла. Рус теле һәм математикадан имтихан бирү һәр укучы өчен мәҗбүри. Ай саен диярлек бу фәннәрдән пробный сынау эшләп карыйлар. Район күләмендә дә язгы каникул вакытында бу фәннәрдән ОГЭ үткәреләчәк.

Укучылар моннан тыш ике фәннән сайлап алу имтиханында катнашалар. Бу уку елында, география, информатика, биология, инглиз теле, җәмгыять белеме, физика фәннәрен сайлап алдылар. Шунысы куанычлы, татар теле фәненнән дә имтихан сайлаучы 5 укучы бар. Консультацияләр графигы төзелде, барлык фәннәрдән дә дәрестән тыш вакытта консультацияләр үткәрелә.

Яшьләрнең игътибарын авыл хуҗалыгына, игенчелеккә юнәлтү максатыннан, Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең 9 нчы сыйныф укучылары “Игенче” агрокомплексына сәяхәткә барды. Укучылар өчен бу көтелмәгән яңалык булды. Анда безне хуҗалык җитәкчесе Хәбибуллин Рөстәм Җәүдәтович каршы алды. Ул ипинең өстәлгә ничек килүе турында яратып һәм кызыклы итеп сөйләде. Хуҗалыкта үстерелгән җитен һәм аның үзенчәлекләре белән таныштырды. Алга таба укучылар белән иген-кырларга кузгалдык. Бәрәңге уңышы, кукуруздан терлеккә ризык әзерләү нечкәлекләре турында бик җентекләп сөйләде Рөстәм Җәүдәтович. Вакытның ничек үткәнен дә сизмичә, илһам, көч алып кайттык без “Игенче” кырларыннан. Әлеге сәяхәт укучылар күңелендә әле озак сакланыр.

Менә шундый файдалы да, мәгънәле дә, эшлекле дә сәяхәт өчен “Игенче” агрокомплексы хуҗаларына һәм директорыбыз Гарипова Гөлнара Фидаил кызына олы рәхмәтебезне җиткерәбез.